**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.07.2020 штп Балык Бистәсе № 150пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 октябрендәге 233пи номерлы карары белән расланган «2018 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә законсыз эшкуарлыкны профилактикалау һәм аңа каршы тору максатларында«Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 октябрендәге 233пи номерлы карары белән расланган «2018 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) «Программа бурычлары» дигән 7 юлына түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8)законсыз эшкуарлыкка профилактика һәм каршы тору».

1.2.) түбәндәге эчтәлекле 8 бүлек өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **8 нче бурыч: законсыз эшкуарлыкны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш** | | | | | | | | | | |
| **8.1.** Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга мәгълүмат җиткерүне, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү, семинарлар һәм конференцияләр уздыру, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре һәм башка ысуллар белән җитәкчелек әзерләү һәм бастырып чыгару юлы белән гамәлгә ашыру. | Территориаль үсеш бүлеге, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Казан территориаль органы (килешү буенча), Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең ТО (килешү буенча), җирлекләр башлыклары (килешү буенча) | 2020 | | | | | | - | - | - |
| **8.2.** Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта - гамәлдәге актларга кертелгән мәҗбүри таләпләрне, аларны гамәлгә кертү срокларын һәм тәртибендә кертелгән үзгәрешләрне билгеле торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге турында шәрехләр әзерләү һәм тарату, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәүне гамәлгә кертүгә һәм тәэмин итүгә юнәлдерелгән тиешле оештыру, техник чаралар уздыру турында тәкъдимнәр | Территориаль үсеш бүлеге, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Казан территориаль органы (килешү буенча), Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең ТО (килешү буенча), җирлекләр башлыклары (килешү буенча) | 2020 | | | | | | - | - | - |
| **8.3.** Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр бирү | Территориаль үсеш бүлеге, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Казан территориаль органы (килешү буенча), Роспотребнадзор идарәсенең ТО (килешү буенча) | 2020 | | | | | | - | - | - |

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru.веб-адрес буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Л. Исланов